**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 301-37 «20» сентябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 81-10 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 81-10 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә (14.12.2021 №103-12, 25.02.2022 №118-15, 08.06.2023 №229-25, 25.10.2023 №244-27, 17.04.2024 №280-33 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.3. бүлегенең 109 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«109. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча Федераль законның 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы 90 статьясының 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.».

1.2. 4.5 бүлегенең 126 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"126. Рейд тикшерүе бары тик прокуратура органнары белән килешү нигезендә генә үткәрелергә мөмкин, моңа Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3 - 6 пунктлары һәм 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә рейд уздыру очраклары керми.».

1.3. 4.7 бүлегенең 138 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«138. Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килешү нигезендә үткәрелергә мөмкин, моңа Федераль законның 66 статьясындагы 1 өлешенең 3 - 6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 12.1 өлешләре нигезендә 289-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздыру очраклары керми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе,

депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин